Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

28 август 2019 ел №166

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 15 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында» 116 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Федераль законның 9 статьясына үзгәрешләр кертү турында «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турында аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 15 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон, Әлмәт муниципаль районы шәһәр Уставының 29 статьясы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 116 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 2 октябрендәге 141 номерлы, 2014 елның 19 ноябрендәге 151 номерлы, 2015 елның 6 маендагы 179 номерлы, 2015 елның 20 ноябрендәге 13 номерлы, 2016 елның 8 ноябрендәге 49 номерлы, 2018 елның 31 маендагы 122 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 126 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

- «- I һәм II группа инвалидлар, балачактан инвалидлар, инвалид балалар, өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган физик затлар, эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата.

Салым түләүчеләр-салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына ташлама бирү турында гариза бирә, шулай ук салым түләүче салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы хокукын раслый торган документлар булып түбәндәгеләр тора: әлеге салым буенча салым түләүче дип танылган физик затның шәхесен таныклаучы документ, шулай ук инвалидлык турында белешмә, аның исеменә бирелгән күп балалы яисә өч һәм аннан күбрәк балалы гаилә таныклыгы, уллыкка бала алучы ата-ана таныклыгы»;

1.2. 2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен алынган (бирелгән), эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләре, шулай ук 2017 елның

29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык, яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент»;»;

1.3. 2 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата 0,07 процент»;»;

1.4. 4 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 1.1 пункты рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла. Әлеге карарның 1.2, 1.3 пунктлары 2020 елның 1 гыйнвареннән үз көченә керә, әлеге карарның 1.4 пункты 2021 елның 1 гыйнвареннән, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Хәмидуллин Ф.Р.).

Шәһәр башлыгы урынбасары А.М. Токарев